ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫ£
ЭТИЛ СПИРТЫ ҺЪМ АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ЌИТЕШТЕРYНЕ,
ЪЙЛЪНЕШТЪ ЙЇРТYНЕ,
СЫЙФАТЫН ДЪYЛЪТ ТИКШЕРYЕН
ТЪЭМИН ИТY ҺЪМ КУЛЛАНУЧЫЛАР
ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА
ДЪYЛЪТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы Д¥YЛ¥Т алкоголь инспекциясе)

# БОЕРЫК

23.05.2016 № 12-08/39

Гражданнарны матди яктан кызыксындыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 20 гыйнвар, 2016 ел, №44-р боерыгын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы территориясендә этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә закон бозу фактлары турында хәбәр итүче гражданнарны матди яктан кызыксындыру максатыннан чыгып, боерык бирәм:

1. Расларга:

Татарстан Республикасы территориясендә этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә закон бозу фактлары турында хәбәр итүче гражданнарга матди түләүләрне хәл итү тәртибен (кушымта итеп бирелә).

2. Хокук бүлегенә (Б.Г.Эйдинов) бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алуга җибәрергә.

3. “Гражданнарны матди яктан кызыксындыру турында” 29.01.2016 ел, №12-07/8 Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасары Р.А.Арслановка йөкләргә.

**Җитәкче** **И.А.Марченко**

Татарстан Республикасы Дәүләт
алкоголь инспекциясенең
«____» май, 2016 ел, № ____
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә закон бозу фактлары турында хәбәр итүче гражданнарга матди түләүләрне хәл итү

**ТӘРТИБЕ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы территориясендә этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә закон бозуларны ачыклауга ярдәм иткән гражданнарга матди түләүләр шартларын һәм ысулын (алга таба - Тәртип) билгели.

1.2. Тәртипнең көче 2016 елның 1 гыйнварыннан 2016 елның 31 декабренә кадәрге чорда килеп чыккан мөнәсәбәтләргә кагыла.

1.3. Татарстан Республикасы территориясендә этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә закон бозуларны ачыклауга ярдәм иткән гражданнарга матди түләүләрне оештыручы булып Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тора.

1.4. Түләүләр, бу максатка Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә бүлеп бирелгән средстволар чикләрендә, Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә.

1.5. Тәртипнең гамәлдә булуы Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе хезмәткәрләренә, шулай ук аларның гаиләләре әгъзаларына (ире, хатыны, әти-әнисе, балалары) кагылмый.

## 2. Төп билгеләмәләр

2.1. Бу Тәртипнең максатлары өчен Татарстан Республикасы территориясендә этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә закон бозу физик яки юридик затның, хосусый эшмәкәрнең, Татарстан Республикасы территориясендә этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә закон бозуга бәйле булып, закон нигезендә административ җәза яки җинаять җәзасы күздә тотылган хокукка каршы гамәлләрен аңлата.

2.2. Мөрәҗәгать итүче – Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (uslugi.tatarstan.ru) “Халык контроле” бүлегендә (алга таба - “Халык контроле” Дәүләт мәгълүмат системасы) “Сәүдә кагыйдәләрен бозу”, “Җәмәгать тыкланувы” яки “Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне законсыз җитештерү һәм (яки) әйләнеше” категорияләрендә тиешле мәгълүмат урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы территориясендә этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә закон бозу турында хәбәр иткән Россия Федерациясе гражданины.

2.3. Матди түләү – мөрәҗәгать итүчегә 1000 (бер мең), 2000 (ике мең) или 3000 (өч мең) сум күләмендә бер тапкыр түләнелә торган түләү (физик затлар кеременә салым чигерүеннән соң).

## 3. Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә закон бозу фактын раслау

3.1. Мөрәҗәгать итүче “Халык контроле” бүлегендә “Сәүдә кагыйдәләрен бозу” яки “Җәмәгать тыкланувы” категориясендә этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә закон бозу турында заявка урнаштырганнан соң Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең

контрольлек-инспекция бүлеге әлеге заявканы, асылын карап тикшерү өчен, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органнарыннан берсенә (мөрәҗәгать итүче күрсәткән закон бозу урыны адресына бәйле рәвештә) җибәрә.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең контрольлек-инспекция бүлеге, “Халык контроле” Дәүләт мәгълүмат системасына алынып, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан карап тикшерелгән этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә закон бозу турында заявкаларны учетка алуны (№1 кушымта) хәл итә.

3.2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе территориаль органының вәкаләтле вазыйфаи затлары, үзләренә тапшырылган вәкаләтләр кысаларында, заявканы алганнан соң өч көн эчендә, мониторинг, планнан тыш тикшерү, административ тикшерү үткәрү юлы белән, тикшерү уздыра.

3.3. Заявканы карап тикшерү йомгаклары турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең контрольлек-инспекция бүлегенә, бу Тәртипнең 3.2 пунктында күрсәтелгән чаралар үткәрелгәннән соң ике көн эчендә, җибәрелә.

Заявкада бәян ителгән мәгълүмат расланган очракта, күрсәтелә:

- контрольлек чарасын үткәрү датасы:
- тартып алынган алкогольле яки спиртлы продукция күләме;
- контрольлек чарасы үткәрелгәндә рәсмиләштерелгән процессуаль документлар;
- әлеге закон бозуга юл куйган хуҗалык итүче субъект турында мәгълүматлар.

3.4. Заявканы карап тикшерү йомгаклары буенча мәгълүмат контрольлек-инспекция бүлеге тарафыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе территориаль органыннан заявканы карап тикшерү йомгаклары буенча мәгълүмат алынганнан соң бер көннән дә соңга калмыйча, “Халык

контроле” Дәүләт мәгълүмат системасында “Сәүдә кагыйдәләрен бозу” яки “Җәмәгать тыклануы” категориясендә билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

3.5. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең контрольлек-инспекция бүлеге, ачыкланган закон бозу факты буенча физик затка, хосусый эшмәкәргә, юридик затка карата административ хокук бозу турында беркетмә тутырылган очракта, административ хокук бозу турында беркетмә тутырылганнан соң бер тәүлектән дә соңга калмыйча, заявкасын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу турында беркетмә тутырылган мөрәҗәгать итүче белән, мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (uslugi.tatarstan.ru) шәхси кабинетын теркәгәндә күрсәткән телефон номеры яки электрон почта адресы аша, элемтәгә керә. Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүчегә, матди түләү турында гариза тапшыру өчен, үзенең яшәү урынына якын булган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органына мөрәҗәгать итәргә тәкъдим ителә.

3.6. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе карамагында мөрәҗәгать итүченең элемтәгә керү өчен мәгълүматлары булмаганда яки аларның дөреслеген тикшерү өчен, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе, аларны алу яки тикшерү максатында, персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык булганда, “Татарстан Республикасы Мәгълүмати технологияләр үзәге”нә мөрәҗәгать итә.

## 4. Түләү шартлары һәм тәртибе

4.1. Түләү административ хокук бозу турында беркетмә яки җинаять эше кузгату турында карар булганда хәл ителә.

4.2. Шул бер үк закон бозу очрагы буенча (“Халык контроле” Дәүләт мәгълүмат системасында бер заявка номеры буенча) түләү бер тапкыр гына, заявканы беренче булып тапшырган (вакыт/дата буенча) мөрәҗәгать итүчегә бирелә.

4.3. Түләү Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе исеменә матди түләү турында гариза алынганнан соң өч көн эчендә җибәрелә торган территориаль орган начальнигының хезмәт язуы нигезендә хәл ителә.

Хезмәт язуына түбәндәге документлар кушып бирелә:

административ хокук бозу турында беркетмә күчермәсе;

Россия Федерациясе гражданинының паспорты күчермәсе;

ИНН күчермәсе;

СНИЛС күчермәсе;

банк реквизитларын күрсәтеп һәм персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык белән, матди түләү турында гариза (№2 кушымта).

Барлык документларны да документларны кабул иткән территориаль орган начальнигы раслый.

4.4. “Халык контроле” Дәүләт мәгълүмат системасының “Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне законсыз җитештерү һәм (яки) әйләнеше” бүлегенә алынган мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү барышында кабул ителгән чаралар буенча мөрәҗәгать итүчеләргә матди түләүләрне хәл итү зарурилыгы турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә шулай ук Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының структур подразделениеләреннән дә алына.

4.5. Түләү Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең финанс контрольлеге бүлегенә бу Тәртипнең 4.3 пунктында күрсәтелгән документлар алынганнан соң 15 эш көне эчендә, банк картасына яки банк бүлегендә ачылган лицевой счетка күчерү юлы белән, хәл ителә.

4.6. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең финанс контрольлеге бүлеге, түләү күчерелгәннән соң бер көн эчендә, мөрәҗәгать итүчегә гаризасында күрсәтелгән номер буенча телефон аша шалтыратып яки күрсәтелгән адресы (электрон почта адресы) буенча язмача (электрон) рәвештә, үзенә тиешле түләүнең күчерелүе турында хәбәр итә.

4.7. Матди түләү күләме билгеләнә:

4.7.1. 3000сум күләмендә:

- җинаять эшен кузгату турында карар булганда, расланылган закон бозу факты турында заявка өчен;

- административ хокук бозу турында төзелгән беркетмә булганда һәм 100 литрдан артыграк күләмдә этил спиртын, алкогольле яки спиртлы продукцияне законсыз әйләнештән алганда, расланылган закон бозу факты турында заявка өчен;

4.7.2. 2000 сум күләмендә:

- юридик затка карата административ хокук бозу турында төзелгән беркетмә булганда, расланылган закон бозу факты турында заявка өчен;

- 10 нан 100 литрга кадәр күләмдә этил спиртын, алкогольле яки спиртлы продукцияне законсыз әйләнештән алганда, расланылган закон бозу факты турында заявка өчен;

- административ хокук бозу турында төзелгән беркетмә булганда, алкогольле продукцияне ваклап сату буенча расланылган лицензиясез эшчәнлек факты турында заявка өчен.

4.7.3. 1000 сум күләмендә:

- физик затка, вазыйфаи затка яки хосусый эшмәкәргә карата административ хокук бозу турында төзелгән беркетмә булганда, расланылган закон бозу факты турында заявка өчен.

4.8. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе, Россия Федерациясе законы нигезендә, түләүләрне хәл итү ягыннан салым агенты булып тора һәм салым түләүчедән физик затлар керемнәренә салымны исәпләү, тотып калу һәм бюджетка күчерү, бюджеттан тыш фондларга взнослар исәпләү һәм күчерү буенча бурычларны үти.

4.9. Финанс елы тәмамланганнан соң түләү алучыга, язмача гаризасы нигезендә, 2-НДФЛ формасы буенча белешмә тапшырыла.

Татарстан Республикасы территориясендә этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә закон бозу фактлары турында хәбәр итүче гражданнарга матди түләүләрне хәл итү тәртибенә №1 кушымта

«Халык контроле» Дәүләт мәгълүмат системасына алына торган мөрәҗәгатьләрне исәпкә кую журналы формасы

| № п/п | Заявканы “Халык контроле” Дәүләт мәгълүмат системасына урнаштыру номеры һәм датасы | Мөрәҗәгать итүче турында мәгълүматлар | Заявканың асылы | Адрес | Территориаль органга җибәрү датасы | Заявканы карап тикшерү турында мәгълүмат (контрольлек чарасын үткәрү датасы, нәтиҗәсе) | Тартып алынган алкогольле һәм спиртлы продукция күләме, л | Административ хокук бозу турында беркетмә тутыру хакында мәгълүмат (№, датасы, кемгә карата тутырылганлыгы) | Матди түләү турында мәгълүмат (мөрәҗәгать итүченең ФИО, матди түләүне алу датасы һәм аның күләме) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы территориясендә этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә закон бозу фактлары турында хәбәр итүче гражданнарга матди түләүләрне хәл итү тәртибенә №2 кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт
алкоголь инспекциясе җитәкчесе
И.А.Марченкога
____________________________тан
_______________________________
паспорт________________________
_______________________________
теркәлү адресы _____________
_______________________________
эл.почта адресы_________________
_______________________________
элемтә өчен телефоны____________
_______________________________

Матди түләү турында гариза

“Халык контроле” Дәүләт мәгълүмат системасына урнаштырылып, гамәлдәге законны бозу турында ___________________________________________________ расланган заявка (заявка № _____________) өчен түбәндәге банк реквизитлары буенча,________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
______________күләмендә, матди түләүне хәл итүегезне сорыйм.

“Персональ мәгълүматлар турында” 27 июль, 2006 № 152-ФЗ Федераль закон нигезендә, персональ мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалык бирәм.

Кушып бирәм:
Россия Федерациясе гражданины паспорты күчермәсен;
ИНН күчермәсе;

СНИЛС күчермәсен.

дата имза